# ЗАКОН
## Республики Татарстан

**О внесении изменений в статьи 4 и 5 Закона Республики Татарстан «Об инвестиционном налоговом кредите в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 февраля 2013 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 68-ЗРТ «Об инвестиционном налоговом кредите в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2011, № 10 (I часть), 2012, № 6 (I часть) следующие изменения:

1) статью 4 изложить в следующей редакции:

«Статья 4. **Основания и условия предоставления инвестиционного налогового кредита в Республике Татарстан**

1. Инвестиционный налоговый кредит может быть предоставлен организации, состоящей на учете в налоговых органах и осуществляющей хозяйственную деятельность на территории Республики Татарстан, по следующим основаниям:

1) при наличии одного из оснований, установленных пунктом 1 статьи 67 Налогового кодекса Российской Федерации;

2) при осуществлении этой организацией строительства нового производства и (или) реконструкции существующего производства.

2. Основания для получения инвестиционного налогового кредита должны быть документально подтверждены организацией.

3. Инвестиционный налоговый кредит предоставляется на срок от одного года:

1) до трех лет включительно – для организаций, выполняющих особо важный заказ по социально-экономическому развитию Республики Татарстан или предоставляющих особо важные услуги населению либо выполняющих государственный оборонный заказ;

2) до четырех лет включительно – для инвестиционных проектов, при которых капитальные вложения не превышают 350 миллионов рублей;

3) до пяти лет включительно – для инвестиционных проектов, при которых капитальные вложения превышают 350 миллионов рублей, но не превышают 800 миллионов рублей;

4) до семи лет включительно – для инвестиционных проектов, при которых капитальные вложения превышают 800 миллионов рублей.

4. Погашение суммы инвестиционного налогового кредита и начисленных процентов входит в срок предоставления инвестиционного налогового кредита и составляет:

1) не более трех лет – для инвестиционных проектов, указанных в пунктах 1 – 3 части 3 настоящей статьи;

2) не более шести лет – для инвестиционных проектов, указанных в пункте 4 части 3 настоящей статьи.

5. Инвестиционный налоговый кредит предоставляется:

1) по основаниям, указанным в подпунктах 1, 5 пункта 1 статьи 67 Налогового кодекса Российской Федерации, – на сумму кредита, составляющую 100 процентов стоимости приобретенного организацией оборудования, используемого исключительно для перечисленных в этих подпунктах целей;

2) по основанию, указанному в подпункте 2 пункта 1 статьи 67 Налогового кодекса Российской Федерации, – на сумму кредита, определяемую по соглашению между уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в сфере регулирования и предоставления государственной поддержки инвестиционной деятельности (далее – уполномоченный орган) и организацией, но не более 50 процентов от стоимости инвестиционного проекта;

3) по основаниям, указанным в подпунктах 3, 4 пункта 1 статьи 67 Налогового кодекса Российской Федерации, – на сумму кредита, определяемую по соглашению между уполномоченным органом и организацией, но не более 10 процентов от стоимости государственного контракта;

4) по основанию, указанному в подпункте 6 пункта 1 статьи 67 Налогового кодекса Российской Федерации, – на сумму кредита, составляющую не более 100 процентов суммы расходов на капитальные вложения в приобретение, создание, дооборудование, реконструкцию, модернизацию, техническое перевооружение амортизируемого имущества, предназначенного и используемого для осуществления резидентами зон территориального развития инвестиционных проектов в соответствии с Федеральным законом от 3 декабря 2011 года № 392-ФЗ «О зонах территориального развития в Российской Федерации и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации»;

5) по основанию, указанному в пункте 2 части 1 настоящей статьи, – на сумму кредита, определяемую по соглашению между уполномоченным органом и организацией, но не более 10 процентов от стоимости инвестиционного проекта.

6. По основаниям, указанным в подпунктах 1, 2, 5, 6 пункта 1 статьи 67 Налогового кодекса Российской Федерации и пункте 2 части 1 настоящей статьи, сумма кредита, накопленная в течение налогового периода, не может превышать сумму налога, подлежащего уплате организацией в рамках инвестиционного

проекта за этот налоговый период в соответствии с бизнес-планом, а также 50 процентов размеров соответствующих платежей по налогу, определенных по общим правилам без учета наличия договоров об инвестиционном налоговом кредите за этот налоговый период.

7. Процентная ставка за пользование инвестиционным налоговым кредитом устанавливается в размере одной второй ставки рефинансирования Центрального банка Российской Федерации, действующей на момент заключения договора об инвестиционном налоговом кредите.

8. Решение о предоставлении инвестиционного налогового кредита принимается при условии предоставления организацией обеспечения, достаточного для покрытия задолженности по инвестиционному налоговому кредиту, в том числе процентов за пользование инвестиционным налоговым кредитом.

9. Способами обеспечения исполнения обязательств по возврату инвестиционного налогового кредита могут быть залог имущества либо поручительство.

10. В отношении имущества, являющегося предметом залога, передаваемого в порядке, предусмотренном статьей 73 Налогового кодекса Российской Федерации, организацией заключается договор имущественного страхования. Срок действия договора имущественного страхования не может быть менее срока действия договора об инвестиционном налоговом кредите.

11. Инвестиционный налоговый кредит предоставляется в случаях отсутствия:

1) у организации задолженности по налогам и сборам, пеням и штрафам в бюджеты бюджетной системы Российской Федерации;

2) иных форм государственной поддержки Республики Татарстан, предоставленной организации для реализации инвестиционного проекта, являющегося основанием для предоставления инвестиционного налогового кредита.

12. Размер средств, направляемых на предоставление инвестиционного налогового кредита, устанавливается законом о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год и плановый период.»;

2) в части 1 статьи 5 слова «исполнительной власти Республики Татарстан в сфере регулирования и предоставления государственной поддержки инвестиционной деятельности» исключить.

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань, Кремль
11 марта 2013 года
№ 16-ЗРТ

Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында”
Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына
үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында” 2011 елның 10 октябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4 статья. **Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирү нигезләре һәм шартлары**

1. Инвестицияле салым кредиты салым органнарында исәптә торучы һәм Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмага түбәндәге нигезләр буенча бирелергә мөмкин:

1) Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 пунктында билгеләнгән нигезләрнең берсе булганда;

2) әлеге оешма тарафыннан яңа производство төзү һәм (яисә) гамәлдәге производствоны реконструкцияләү башкарылганда.

2. Инвестицияле салым кредиты алу өчен нигезләр оешма тарафыннан документаль расланган булырга тиеш.

3. Инвестицияле салым кредиты бер елдан алып түбәндәге срокка бирелә:

1) өч елга кадәр, шул елны да кертеп, – Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча аеруча мөһим заказ үтәүче яисә халыкка аеруча мөһим хезмәтләр күрсәтүче йә дәүләт оборона заказын үтәүче оешмалар өчен;

2) дүрт елга кадәр, шул елны да кертеп, – капитал салулар 350 миллион сумнан артык булмаган инвестиция проектлары өчен;

3) биш елга кадәр, шул елны да кертеп, – капитал салулар 350 миллион сумнан артык булган, әмма 800 миллион сумнан артып китмәгән инвестиция проектлары өчен;

4) җиде елга кадәр, шул елны да кертеп, – капитал салулар 800 миллион сумнан артык булган инвестиция проектлары өчен.

4. Инвестицияле салым кредитын һәм исәпләнгән процентларны түләү вакыты инвестицияле салым кредиты бирү срогына керә һәм түбәндәгене тәшкил итә:

1) өч елдан артык түгел – әлеге статьяның 3 өлешендәге 1 – 3 пунктларында күрсәтелгән инвестиция проектлары өчен;

2) алты елдан артык түгел – әлеге статьяның 3 өлешендәге 4 пунктында күрсәтелгән инвестиция проектлары өчен.

5. Инвестицияле салым кредиты түбәндәгечә бирелә:

1) Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 пунктының 1, 5 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча – бу пунктчаларда санап үтелгән максатларда гына файдаланыла торган, оешма тарафыннан сатып алынган җиһаз бәясенең 100 процентын тәшкил итүче кредит суммасына;

2) Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инвестиция эшчәнлеген җайга салу һәм дәүләт ярдәмен күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле органы (алга таба – вәкаләтле орган) һәм оешма арасындагы килешү буенча билгеләнә торган кредит суммасына, әмма инвестиция проекты бәясенең 50 процентыннан артык түгел;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 пунктының 3, 4 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча – вәкаләтле орган һәм оешма арасындагы килешү буенча билгеләнә торган кредит суммасына, әмма дәүләт контракты бәясенең 10 процентыннан артык түгел;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 пунктының 6 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча – “Россия Федерациясендә территориаль үсеш зоналары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2011 елның 3 декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвестиция проектларын территориаль үсеш зоналары резидентлары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен каралган һәм файдаланылучы, амортизацияләнә торган мөлкәтне сатып алуга, булдыруга, җиһазлап бетерүгә, реконструкцияләүгә, модернизацияләүгә, техник яктан яңадан коралландыруга капитал салулар чыгымнары суммасының 100 процентыннан артык булмаган кредит суммасына;

5) әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән нигез буенча – вәкаләтле орган һәм оешма арасындагы килешү буенча билгеләнә торган кредит суммасына, әмма инвестиция проекты бәясенең 10 процентыннан артык түгел.

6. Салым чоры дәвамында тупланган кредит суммасы, Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 пунктының 1, 2, 5, 6 пунктчаларында һәм әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча, бизнес-план нигезендә бу салым чорында оешма тарафыннан инвестиция проекты

кысаларында түләнергә тиешле салым суммасыннан, шулай ук, бу салым чоры өчен инвестицияле салым кредиты турында шартнамәләрнең булуын исәпкә алмыйча, гомуми кагыйдәләр буенча билгеләнгән тиешле салым түләүләре күләмнәренең 50 процентыннан артып китә алмый.

7. Инвестицияле салым кредитыннан файдаланган өчен процент ставкасы инвестицияле салым кредиты турындагы шартнамә төзелгән вакытка Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдәге рефинанслау ставкасының икедән бере күләмендә билгеләнә.

8. Инвестицияле салым кредиты бирү турында карар инвестицияле салым кредиты буенча бурычны, шул исәптән инвестицияле салым кредитыннан файдаланган өчен процентларны каплау өчен җитәрлек дәрәҗәдә оешма тарафыннан тәэмин ителү шарты үтәлгәндә кабул ителә.

9. Инвестицияле салым кредитын кире кайтару йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү алымнары мөлкәт залогы йә поручительлек булырга мөмкин.

10. Оешма Россия Федерациясе Салым кодексының 73 статьясында каралган тәртиптә тапшырыла торган залог предметы булып торган мөлкәткә карата мөлкәт иминияте шартнамәсе төзи. Мөлкәт иминияте шартнамәсенең гамәлдә булу срогы инвестицияле салым кредиты турындагы шартнамәнең гамәлдә булу срогыннан ким була алмый.

11. Инвестицияле салым кредиты түбәндәгеләр булмаганда бирелә:

1) оешманың Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлары;

2) инвестицияле салым кредитын бирү өчен нигез булып торган инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен оешмага бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт ярдәменең башка рәвешләре.

12. Инвестицияле салым кредиты бирүгә юнәлдерелә торган акчалар күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон белән билгеләнә.";

2) 5 статьяның 1 өлешендә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инвестиция эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен җайга салу һәм бирү өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләрен "вәкаләтле орган" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2013 елның 11 марты
№ 16-ТРЗ